| | |
|---|---|
| **ГЛАВА КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 ел 2 ноябрь Кәүҗияк авылы № 2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегендә Бикмәт авылы гражданнарының 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 18 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Бикмәт авылындагы фельдшер-акушерлык пункты бинасында 2020 елның 14 ноябренә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Кәүҗияк авылы җирлеге Бикмәт авылында теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 200 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

- Бикмәт авылына урам яктырткычлары сатып алу;
- Бикмәт авылы территориясендә үлән чабу;
- каты көнкүреш калдыкларын күмү;
- район газетасы «Сарман»да некрологларны бастырып чыгару.

ӘЙЕ ЮК?».

3. Гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгән көннән алып 7 көн эчендә урнаштырырга.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ә.Хөснетдинов